ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.05.2020 Олы Кайбыч ав. № 248

Кайбыч муниципаль районында 2019-2020 еллар ягу сезоны тәмамлану һәм 2020-2021 еллар көзге-кышкы ягу чорына әзерләнү турында

РФ Хөкүмәтенең «Милекче һәм кулланучыларга күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары нигезендә һәм торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрен, Цельсий буенча 8 градустан югарырак уртача тәүлеклек тышкы һава температурасы артык урнашу сәбәпле, ягулык-энергетик комплекс һәм социаль мәдәни көнкүреш объектларын 2019-2020 еллар көзге-кышкы ягу чорына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРДЕ:

1. Кайбыч муниципаль районының социаль объектларын, торак фондын һәм башка кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләргә һәм оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1.1. 2019-2020 елгы ягу сезонын 2020 елның 30 апреленнән тәгалләргә.

1.2. Пар казаннары бинасында, үзәк җылылык пунктларында , җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрендә һәм эчке инженер системаларында объектларны көзге-кышкы ягу чорына әзерләү чаралары нигезендә ремонтлау һәм профилактика эшләрен башларга.

2. Объектларны 2020 - 2021 елларның көзге-кышкы чорына әзерләүне 2020 елның 15 сентябренә тәгалләргә.

3. Постановление Исполнительного комитета Кайбицкого муниципального района Республики Татарстан от 13.04.2020 №199 «Об окончании отопительного сезона 2019-2020 г.г. и подготовке к отопительному сезону в осенне-зимний период 2020-2021 г.г. в Кайбицком муниципальном районе» признать утратившим силу. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында 2019-2020 елгы ягу сезонын тәмамлау һәм 2020 елның көзге-кышкы чорында җылыту сезонына әзерлек турында» 2014 елның 13 апрелендәге 199 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 30 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров